**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**21 ноябрь, 2023 ел** **№ 349**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2023 елның 27 октябрендәге 02-08-03 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 октябрендәге 116 номерлы карарына (31.02.2022 №144, 07.06.2023 №302 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 3.6.4 пунктын өстәргә:

«3.6.4. Контрольләнә торган зат контроль (күзәтчелек) органга аңа карата профилактик визиты үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы (алга таба - контрольдә тотыла торган зат гаризасы).

Контроль (күзәтчелек) орган контрольдә тотыла торган затның гаризасын күрсәтелгән гаризаны теркәү датасыннан ун эш көне эчендә карый һәм профилактик визит уздыру турында йә контроль (күзәтчелек) органының матди, финанс һәм кадрлар ресурсларын, контроль объекты куркынычлык категориясен исәпкә алып, аны уздырудан баш тарту турында карар кабул итә, бу хакта контрольдә тотыла торган затка хәбәр итә.

Контроль (күзәтчелек) орган контрольдә тотыла торган зат гаризасы буенча профилактик визитны түбәндәге нигезләрнең берсе буенча уздырудан баш тарту турында карар кабул итә:

1) контрольдә тотыла торган заттан профилактик визит уздыру турында гаризаны кире алу турында хәбәрнамә килде;

2) контрольдә тотыла торган затның гаризасы бирелгән датага кадәр ике ай эчендә контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан әлеге контрольдә тотыла торган затка карата профилактик визит үткәрүдән баш тарту турында карар кабул ителде;

3) контрольдә тотыла торган затның гаризасы бирелгән датага кадәр алты ай эчендә профилактик визитны үткәрү, эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча контрольдә тотыла торган зат булмауга йә профилактик визитны үткәрүнең мөмкин булмавына китергән контрольдә тотыла торган затның башка гамәлләренә (гамәл кылмавына) бәйле рәвештә, мөмкин булмады;

4) контрольдә тотыла торган зат гаризасында контроль (күзәтчелек) органы вазыйфаи затларының яисә аларның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар, цензуралы булмаган яисә мыскыллы сүзләр бар.

Контроль (күзәтчелек) органы контрольдә тотыла торган затның гаризасы буенча профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, егерме эш көне эчендә контрольдә тотыла торган зат белән профилактик визит уздыру датасын мондый килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән килештерә һәм закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян (зарар) китерү куркынычын профилактикалау программасына шундый профилактик визитны кертүне тәэмин итә.»

1.2. Кушымтаның 4.2.15 пунктында 2.9 пунктчасының 7 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы вәкаләтле вәкил» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы вәкаләтле вәкил» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов